# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2022 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Таллы-Бүләк торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**06 декабрь 2021 ел** **№2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Карамалы авыл җирлеге Таллы-Бүләк торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Таллы-Бүләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Таллы Бүләк авылында урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергияне саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- Таллы Бүләк авылында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Таллы Бүләк авылында зират территориясен киртәләү өчен материаллар (төзелеш материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү) алу.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Карамалы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Карамалы авыл җирлеге башлыгы А.Р. Ногманов